КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1291

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 315 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 315 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 663 нче; 2006 ел, 2 май, 216 нчы; 2008 ел, 27 июнь, 449 нчы; 2009 ел, 13 июль, 491 нче; 2010 ел, 11 июнь, 465 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1035 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 29 август, 724 нче; 2011 ел, 29 август, 726 нчы; 2012 ел, 8 сентябрь, 761 нче; 2013 ел, 19 март, 190 нчы; 2014 ел, 1 февраль, 54 нче; 2014 ел, 1 февраль, 150 нче; 2014 ел, 16 май, 325 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1042 нче; 2015 ел, 30 июнь, 472 нче; 2016 ел, 13 май, 301 нче; 2016 ел, 22 октябрь, 769 нчы; 2016 ел, 30 ноябрь, 880 нче; 2017 ел, 22 май, 295 нче; 2018 ел, 9 апрель, 223 нче; 2018 ел, 11 июль, 562 нче; 2018 ел, 10 декабрь, 1098 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә товар базарларында көндәшлекне үстерү максатларының һәм бурычларның өстенлеген тәэмин итә»;

3.2 пунктның утыз беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда:».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин